СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«29» октябрь 2024ел** **№117**

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 25 февралендәге 44 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (11.12.2023 №90 үзгәрешләре белән)**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында “Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 февралендәге 44 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә (11.12.2023 N90 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.6 пунктның 4.6.8 подпунктын түбәндәгечә бәян итәргә:
«4.6.8. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12_1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми»;

1.2. 4.8 пунктның 4.8.4. подпунктын түбәндәгечә бәян итәргә:
«4.8.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31

июлендәге 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Лутфуллин Ф.Ф.

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012660